ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

02.08.2018 г. Казань № 98-од

2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында

Алдынгы архив технологияләрен гамәлгә кертү һәм хәзерге заман җайланмаларын һәм техникасын үзләштерү, архив өлкәсендә тотрыклы югары нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итүче муниципаль архивларга ярдәм күрсәтү, муниципаль берәмлекләрдә архив эшен оештыру өлешендә уңай тәҗрибә тарату, муниципаль архивлар җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен һөнәри үстерү исәбенә Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм бүтән архив документларын исәпкә алу, туплау, аларның сакланышын тәэмин итү һәм алардан файдалану сыйфатын арттыруны стимуллаштыру максатларында б о е р ы к б и р әм:

1. 2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс (алга таба – конкурс) оештырырга һәм аны 2018 елның 20 сентябреннән 19 октябренә кадәр уздырырга.

2. 2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында кушымта итеп бирелүче нигезләмәне расларга.

3. Архив эше һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү бүлеге конкурска оештыру-методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш.

4. «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы буенча 2017 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 06.04.2017 № 045-од боерыгының үз көчен югалтуын танырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча
дәүләт комитетының
02.08.2018 № 98-од
боерыгы белән расланды

2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына
грант ярдәме алуга конкурс турында
НИГЕЗЛӘМӘ

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында әлеге Нигезләмә «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.06.2016 № 395 карары белән расланган «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

Конкурста катнашучылар – грантны гамәлгә куючы (Грант бирүче) һәм Грант алучы.

Грантны гамәлгә куючы (Грант бирүче) – грантлар бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты.

Грантка дәгъва кылучы – Татарстан Республикасы муниципаль архивы.

Грант алучы – әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүче, конкурс сайлап алуын узган һәм әлеге Нигезләмәнең 1.6 пунктында күрсәтелгән «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм бүтән документларны саклауны тәэмин итү проектларына ярдәм» номинациясендә 1 нче урыннан алып 7 нче урынны һәм (яисә) «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм бүтән документларны популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм» номинациясендә 1 нче урыннан алып 8 нче урынны яулаган Татарстан Республикасы муниципаль архивы.

Грант – әлеге Нигезләмәнең 1.6 пунктында күрсәтелгән һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) расланган бюджет йөкләмәләре чикләрендә Грант бирүче тарафыннан сатып алынган җайланмаларны һәм техниканы муниципаль берәмлекләрдә архив эшен үстерүгә юнәлгән чараларны гамәлгә ашыру өчен грант алучыларга билгеле бер вакытта тапшыру.

1.2. Конкурс гавами характерда була һәм, архив эше өлкәсендә муниципаль архивлар казанышларын исәпкә алып, ачык һәм коллегиаль принциплар нигезендә уздырыла.

1.3. Грант алучыларны конкурс сайлап алуы (алга таба – конкурс сайлап алуы) максаты – Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм бүтән архив документларын исәпкә алу, тулыландыру сыйфатын арттыруны, аларның сакланышын һәм алардан файдалануны алдынгы архив технологияләрен гамәлгә кертү һәм заманча җайланмаларны һәм техниканы үзләштерү, архив эше өлкәсендә югары нәтиҗәләргә тотрыклы рәвештә ирешүне, муниципаль берәмлекләрдә архив эшен оештыру өлешендә уңай тәҗрибә таратуны, муниципаль архивлар җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен үстерү исәбенә тәэмин итүче муниципаль архивларны стимуллаштыру.

1.4. Конкурс сайлап алуы бурычы – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә архив эше өлкәсен үстерү өчен актуаль һәм социаль әһәмиятле масштаблы проектларны ачыклау һәм алдынгы архив технологияләрен гамәлгә кертүдә югары нәтиҗәләргә тотрыклы рәвештә ирешүне тәэмин итүче муниципаль архивларны бүләкләү.

1.5. Конкурс 2018 елның 20 сентябреннән алып 19 октябренә кадәр уздырыла, шул исәптән:

2018 елның 20 сентябреннән алып 1 октябренә кадәр – Грантка дәгъва кылучыларның Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына язма рәвештә проектларын тапшыру;

2018 елның 3 октябреннән алып 16 октябренә кадәр – Экспертлар советы әгъзалары тарафыннан 2018 елда Грантка дәгъва кылучыларның язма проектларын карау;

2018 елның 17 октябреннән алып 19 октябренә кадәр – Грантка дәгъва кылучыларның проектларын гавами яклаулары.

1.6. Конкурс Грантка дәгъва кылучылар тарафыннан тапшырылган проектлар арасында ике номинация буенча уздырыла:

| Номинация атамасы | Грантлар саны | Проектларны гамәлгә ашыру юнәлешләре | 1 проектка җайланмалар комплекты |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм бүтән архив документлары сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм | 7 грант | Электрон саклагычларда, хәзерге заман архив технологияләрен кулланып, файдалану фонды булдыру | А2+ форматында планетар сканерлауның автоном комплексыннан һәм аңа аксессуарлардан торган 480000 сумлык комплект |
| Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм бүтән документларны популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм | 8 грант | Архив документларын популярлаштыру, алардан файдалану һәм, хәзерге заман архив | Күргәзмә стендлары, видеопроектордан, ноутбуктан, экраннан, аксессуарлардан һәм аларга комплектлаучылардан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | технологияләрен кулланып, тикшеренүчеләрнең аларны (Россия Федерациясе законнар белән чикләнгән документлардан гайре) алу мөмкинлеген тәэмин итү | торган 205000 сумлык комплект |

1.7. Грантка дәгъва кылучылар әлеге Нигезләмә нигезендә бер үк вакытта барлык игълан ителгән номинацияләр буенча (һәр номинациядә бердән дә артык түгел) проектлар тәкъдим итәргә хокуклы, моңа 2017 елда грант ярдәме алган муниципаль архивлар керми. 2017 ел конкурсы йомгаклары буенча Грантлар алучылар 2017 ел конкурсы йомгаклары буенча җиңүчләр проектларын реализацияләү башкарыла торган номинацияләрдә яңа проектлар тәкъдим итмиләр.

1.8. Проектта гамәлгә ашыру проблемалары, максатлары һәм бурычлары куелырга тиеш, аларны гамәлгә ашыру сроклары (кимендә 3 ел) һәм урыны, төп чаралар тасвирламасы, эшләр күләмнәре, көтеләчәк нәтиҗәләр булырга тиеш.

1.9. Конкурска бирелгән проектларны эксперт бәяләвен гамәлгә ашыру һәм җиңүчеләрне билгеләү өчен Экспертлар советы төзелә.

1.10. Конкурста катнашу өчен сайлап алуны уздыру тәртибе, сроклары, шартлары һәм критерийлары турында мәгълүмат «2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында» Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты боерыгы үз көченә кергән көннән 5 (биш) эш көне эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының рәсми сайтында (www. http://arhiv.tatarstan.ru/, Грантлар бүлегендә) урнаштырыла.

## II. Конкурста катнашуга хокук һәм документлар кабул итү тәртибе

2.1. Конкурста Татарстан Республикасы муниципаль архивлары катнашырга хокуклы.

2.2. Конкурста катнашу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына түбәндәгеләр бирелә:

конкурста катнашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзаланган заявка (әлеге Нигезләмәгә кушымта);

Грантка дәгъва кылучының проекты(лары).

Заявка һәм проект(лар) конкурста катнашу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән срокларда Татарстан Республикасы Бердәм электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасында урнаштыру юлы белән, муниципаль район

(шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзаланган йөртү хаты белән җибәрелә.

2.3. Проектта аудио- һәм видеоматериаллар булган очракта, соңгылары кулдан-кулга, почта аша тапшырылырга, конкурста катнашу өчен проектны Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына тапшырган көнне Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының рәсми электрон адресына prm.archive@tatar.ru җибәрелергә мөмкин.

2.4. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту өчен нигез әлеге Нигезләмәнең 1.7, 1.8 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәүдән һәм проектны әлеге Нигезләмәнең 1.5 пункты белән билгеләнгәнчә тапшыру срогын бозудан гыйбарәт була.

2.5. Әлеге Нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә конкурста катнашуга кертелмәгән Грантка дәгъва кылучыларга бу хакта хәбәр итү Грантка дәгъва кылучыларның әлеге Нигезләмәнең 2.2, 2.3 пунктларында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына кертелгән документлар Татарстан Республикасы Дәүләт комитетында теркәлгән көннән 3 (өч) эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

## III. Проектларны гавами яклау тәртибе

3.1. Проектларны гавами яклау вакыты, урыны һәм графигы Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнә һәм, Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштуру юлы белән, әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән гавами яклауның беренче датасына кадәр 7 (җиде) эш көненнән дә соңга калмыйча, Грантка дәгъва кылучыларга җиткерелә.

3.2. Проектны гавами яклау муниципаль архив җитәкчесе яисә бүтән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3. Бер проектны гавами яклауга 10 минуттан артык булмаган вакыт бирелә.

## IV. Конкурска тәкъдим ителгән проектларны бәяләү тәртибе һәм критерийлары

4.1. Муниципаль архивлар проектларын бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

тапшырылган материалларны бәяләү критерийлары нигезендә бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек.

4.2. Грантка дәгъва кылучылар проектларын бәяләү Экспертлар советы әгъзалары тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә эксперт бәяләве методы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Экспертлар советы әгъзасы һәр критерий буенча балларны саный һәм куша.

4.4. Баллар экспертлар битләренә кертелә, Экспертлар советы әгъзасы имзасы белән таныклана һәм Экспертлар советы рәисенә тапшырыла.

4.5. Проектларны бәяләү критерийлары түбәндәгеләр:

проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте (1 баллдан 10 баллга кадәр);

чараларны гамәлгә ашыруга программа-максат алымы (1 баллдан 10 баллга кадәр);

проектның соңгы нәтиҗәсе күләме буенча масштаблыгы (1 баллдан 15 баллга кадәр);

проектның методик эшләнгән булуы, проектны Татарстан Республикасының башка муниципаль архивларында гамәлгә ашыру өчен ишәйтү мөмкинлеге (1 баллдан 10 баллга кадәр);

проектны киләчәктә үстерү перспективасы (1 баллдан 15 баллга кадәр).

4.6. Экспертлар советы әгъзалары әлеге Нигезләмәнең 4.5 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча куелган балларны кушу нәтиҗәләре нигезендә Грантка дәгъва кылучыларның Экспертлар советы рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзаланган йомгак рейтингы формалаштырыла.

4.7. Конкурста катнашучылар җыйган баллар тигез булганда, өстәмә критерийлар кулланыла (2017 ел өчен Татарстан Республикасы Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы Бердәм электрон документлар әйләнеше ведомствоара системасы аша тапшырылган, муниципаль архивка өстенлек бирүче муниципаль архивларның еллык хисаплары буенча түбәндәгеләре булган килеш (бер-бер артлы) билгеләнә:

үткән ел өчен үтәлгән план күрсәткечләре күләме зур булу;

01.01.2018га саклanучы документларның күләме зур булу;

01.01.2018 га туплау чыганаклары саны күп булу.

## V. Экспертлар советын формалаштыру һәм эшчәнлеге тәртибе

5.1. Экспертлар советы архив эше белгечләре, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан Экспертлар советы рәисе, рәисе урынбасары һәм әгъзалары составында тугыз кешедән формалаштырыла.

5.2. Экспертлар советы составы Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

## VI. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү

6.1. Проектларны гавами яклау тәмамланганнан соң 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча, Грантка дәгъва кылучыларның Экспертлар советының йомгак рейтингы нигезендә конкурста җиңүчеләр исемлеге төзелә.

Конкурста җиңүчеләр дип әлеге Нигезләмәнең 1.6 пункты нигезендә «Россия Федерациясе Архив фонды документларының һәм бүтән документларның сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм» номинациясендә беренче 7 позиция һәм (яисә) «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм бүтән документларны популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм» номинациясендә беренче 8 позиция яулаган Грантка дәгъва кылучылар таныла.

6.2. Экспертлар советы карарлары, алар өчен шунда катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән очракта, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, Экспертлар советы рәисе тавышы хәлиткеч була.

6.3. Экспертлар советы утырышлары, совет әгъзаларының гомуми санынnан 2/3се анда катнашкан очракта, тулы хокуклы дип санала.

6.4. Экспертлар советы карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

6.5. Конкурста җиңүче Грантка дәгъва кылучылар исемлеге Экспертлар советы утырышының йомгак беркетмәсе нигезендә, беркетмә имзаланган көннән 3 (өч) эш көннән дә соңга калмыйча, Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана.

6.6. Җиңүчеләр исемлеге боерыкка имза салынган көннән 3 (өч) эш көне эчендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (www. http://arhiv.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

6.7. Конкурска тәкъдим ителгән проектлар муниципаль архивлар җитәкчеләренең шәхси гаризалары нигезендә конкурс уздырган елдан соң килүче елның 31 декабренә кадәрге срокта кире кайтарыла.

## VII. Грантлар алучылар тарафыннан хисапларын тапшыру тәртибе һәм сроклары

7.1. Грант алучылар ел саен, 3 ел дәвамында, Дәүләт комитетына грантлар рәвешендә бирелгән җайланмаларны һәм техниканы максатчан файдалану турында һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 июненә кадәр эшчәнлекләре нәтиҗәләре турында хисаплар тапшыралар.

7.2. Эшчәнлек нәтиҗәләре турындагы хисапта түбәндәге төп позицияләр ачып бирелә:

проектны гамәлгә ашыру тасвирламасы;

«Россия Федерациясе Архив фонды документларының һәм бүтән документларның сакланышын тәэмин итү проектларына ярдәм» номинациясендә:

Россия Федерациясе Архив фонды документларыннан һәм бүтән архив документларыннан электрон файдалану фондын булдыру барышында цифрланган документлар саны;

документларның Татарстан Республикасы Бердәм архив мәгълүмат системасында урнаштырылган электрон күчермәләре саны;

«Татарстан Республикасы Архив фонды документларын һәм бүтән документларны популярлаштыру һәм алардан файдалану проектларына ярдәм» номинациясендә:

электрон файдалану фондын кулланып башкарылган чаралар саны һәм электрон файдалану фондына мөрәҗәгать иткән тикшеренүчеләр саны;

гражданнарның һәм оешмаларның гарызнамәләрен архив документларыннан файдалану фонды исәбенә үтәү сроклары;

барлык номинацияләрдә:

җәмәгатьчелек фикеренә күзәтү (массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәрләре, анкеталаштыру);

фото- һәм видеоматериаллар.

---

2018 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме алуга конкурс турында нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль архивларын үстерү өчен Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының грантларын алуга конкурста катнашу өчен заявка

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Проект атамасы | |
| 2. | Номинация | |
| 3. | Муниципаль архивының тулы атамасы (алга таба – учреждение) | |
| 4. | Муниципаль архив җитәкчесе Ф.Ис.Ат.ис. | |
| 5. | Муниципаль архивның рәсми адресы | |
| 6. | Контакт телефоны, e-mail | |

Заявканы тутыру датасы ______________________

Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе имзасы ________________________Ф.Ис.Ат.ис.